# ЗАКОН
# РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О Счетной палате Республики Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 февраля 2026 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 7 июня 2004 года № 37-ЗРТ «О Счетной палате Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 10 октября 2011 года № 65-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 6; 2011, № 10 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 6 (I часть); 2016, № 4; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 55 (часть I); 2018, № 83 (часть I); 2019, № 19 (часть I), № 49 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2022, № 49 (часть I); 2023, № 27 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 5:

а) часть 1 дополнить предложением следующего содержания: «По истечении срока полномочий Председатель Счетной палаты продолжает исполнять полномочия до назначения нового Председателя Счетной палаты.»;

б) в абзаце первом части 2 слова «выдвижения кандидатур» заменить словами «внесения предложений о кандидатурах»;

в) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. В случае досрочного освобождения от должности Председателя Счетной палаты предложения о кандидатурах на эту должность вносятся в Государственный Совет Республики Татарстан в течение одного месяца со дня указанного освобождения. В случае отклонения внесенных кандидатур на должность Председателя Счетной палаты субъекты, указанные в части 2 настоящей статьи, в течение двух недель вносят предложения о новых кандидатурах. При этом на рассмотрение Государственного Совета Республики Татарстан могут быть внесены те же кандидатуры либо другие кандидатуры.»;

2) в статье 6:

а) в части 2 слово «Кандидатура» заменить словами «Предложение о кандидатуре»;

б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. В случае досрочного освобождения от должности заместителя Председателя Счетной палаты предложение о кандидатуре на эту должность вносится в Государственный Совет Республики Татарстан Председателем Счетной палаты в течение двух недель со дня указанного освобождения. В случае отклонения внесенной кандидатуры Председатель Счетной палаты в течение двух недель вносит предложение о новой кандидатуре. При этом на рассмотрение Государственного Совета Республики Татарстан может быть внесена та же кандидатура либо другая кандидатура.»;

3) часть 3 статьи 7 изложить в следующей редакции:

«3. Предложения о кандидатурах на должности аудиторов Счетной палаты вносятся в Государственный Совет Республики Татарстан Председателем Счетной палаты. В случае отклонения внесенной кандидатуры Председатель Счетной палаты в течение двух недель вносит предложение о новой кандидатуре. При этом на рассмотрение Государственного Совета Республики Татарстан может быть внесена та же кандидатура либо другая кандидатура.»;

4) статью 10 изложить в следующей редакции:

«Статья 10. **Основания досрочного освобождения от должности Председателя Счетной палаты, заместителя Председателя Счетной палаты, аудиторов Счетной палаты**

1. Председатель Счетной палаты, заместитель Председателя Счетной палаты, аудиторы Счетной палаты досрочно освобождаются от должности решением Государственного Совета Республики Татарстан по основаниям, предусмотренным Федеральным законом.

2. Представление о досрочном освобождении от должности Председателя Счетной палаты вносится в Государственный Совет Республики Татарстан Главой (Раисом) Республики Татарстан, представления о досрочном освобождении от должности заместителя Председателя Счетной палаты и аудиторов Счетной палаты вносятся в Государственный Совет Республики Татарстан Председателем Счетной палаты.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ / ГОМУМИ БҮЛЕК — АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казань, Кремль
26 февраля 2026 года
№ 15-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Вәкаләтләр чоры узгач, Хисап палатасы Рәисе яңа Хисап палатасы Рәисе билгеләп куелганга кадәр үз вәкаләтләрен башкаруны дәвам итә.»;

б) 2 өлешнең беренче абзацында «кандидатуралар күрсәтү» сүзләрен «кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хисап палатасы Рәисе вазыйфадан вакытыннан алда азат ителгән очракта, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әлеге вазыйфага кандидатуралар турында тәкъдимнәр күрсәтелгән азат итү көненнән алып бер ай дәвамында кертелә. Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына кертелгән кандидатуралар кире кагылган очракта, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән субъектлар ике атна эчендә яңа кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертә. Бу чакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатуралар йә башка кандидатуралар кертелергә мөмкин.»;

2) 6 статьяда:

а) 2 өлештә «кандидатура» сүзен «кандидатура турында тәкъдим» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хисап палатасы Рәисе урынбасары вазыйфадан вакытыннан алда азат ителгән очракта, Хисап палатасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әлеге вазыйфага кандидатура турында тәкъдим күрсәтелгән азат итү көненнән алып ике атна эчендә кертелә. Кертелгән кандидатура кире кагылган очракта, Хисап палатасы Рәисе ике атна эчендә яңа кандидатура турында тәкъдим кертә. Бу чакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатура йә башка кандидатура кертелергә мөмкин.»;

3) 7 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Хисап палатасы аудиторлары вазыйфаларына кандидатуралар турында тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кертелә. Кертелгән кандидатура кире кагылган очракта, Хисап палатасы Рәисе ике атна эчендә яңа кандидатура турында тәкъдим кертә. Бу чакта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына шул ук кандидатура йә башка кандидатура кертелергә мөмкин.»;

4) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Хисап палатасы Рәисен, Хисап палатасы Рәисе урынбасарын, Хисап палатасы аудиторларын вазыйфадан вакытыннан алда азат итү нигезләре**

1. Хисап палатасы Рәисе, Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Хисап палатасы аудиторлары вазыйфадан вакытыннан алда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән Федераль законда каралган нигезләрдә азат ителәләр.

2. Хисап палатасы Рәисен вазыйфадан азат итү турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кертелә, Хисап палатасы Рәисе урынбасарын һәм Хисап палатасы аудиторларын вазыйфадан вакытыннан алда азат итү турындагы тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Хисап палатасы Рәисе тарафыннан кертелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 26 февраль
№ 15-ТРЗ